**"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«14» ноябрь 2019 ел № 3

**Гажданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Ак Чишмэ авылында Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст.», Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану һәм "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Ак Чишмэ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- вак таш җәеп, юлларны ремонтлау:
(сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
Ак Чишмэ торак пунктында, Карл Маркс урамы;
- Ак Чишмэ торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту

« ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча 2019 нчы елның 14 нче ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 32 граждан кертелгән; гражданнар җыенында катнашучы 24 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе " позициясе өчен»- барлыгы 24 кеше тавыш бирде;
“Юк” дип тавыш бирүче булмады.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Ак Чишмэ авылында үткән гражданнар жыенын- уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Ак Чишмэ авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Ак Чишмэ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- вак таш җәеп, юлларны ремонтлау:
(сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
Ак Чишмэ торак пунктында, Карл Маркс урамы;
- Ак Чишмэ торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту
.

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге
Советы рәисе И.З.Исмагилов